СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
№ 3-43

РЕШЕНИЕ
«18» сентябрь 2019 ел.

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

01.04.2019 елдагы № 48 – ФЗ санлы «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы Федераль законы,Татарстан Республикасының 13.07.2018 елның № 50-ТРЗ санлы «Татарстан Республикасының дәүләт гражданнары хезмәте һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы"ның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турындагы законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы 2016 елның 3 мартындагы 1-6 санлы Татарстан Республикасы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә (18.11.2016 №2-14, 15.05.2017 №1-18, 28.07.2017 №2-19, 14.11.2017 №2-23, 05.06.2018 №2-29, 13.08.2018 №2-31, 20.11.2018 №3-34, 14.12.2018 №2-35, 21.03.2019 №1-37) Совет карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12.3 пунктның 6 пунктчасы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ»;

1.2. 25.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"25.8 өлешендә каралган конкурсны үткәрү турында мәгълүматта белем алганнан соң Гражданнар алмаштырылырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәре; әлеге вазыйфаларга квалификация таләпләре; 25.8 өлеше нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге күрсәтелә; кабул итү урыны һәм вакыты; конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен файдаланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (конкурс комиссиясе тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса), шулай ук башка мәгълүмат материаллары да булырга мөмкин.»;

1.3. Пункт 25.16. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе дәгъвачыларны 25.11 өлешенең 1-6 пунктларында күрсәтелгән документлар нигезендә, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары индивидуаль әңгәмә, тест һәм (яки) язмача биремне күздә тота.».

2. . Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сәләхетдиновка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / И.Н.Сәләхетдинов/